# ГОМЕРЛӘР ЗАЯ УЗМАСЫН

*З.Нагаева*
*З.Нагаева көе*

Кояш җылысын тоймаса,
Ачылмый гөлләр.
Айның да йолдызы барга
Яктыра төннәр.

*Кушымта:*
Беребез өчен беребез кирәк,
Бергә барыбыр җиңелерәк.
Дөньялар ничек кенә
Авыр булмасын,
Пар канатларың сынмасын,
Гомерләр зая узмасын.
Кәккүкләр бар парлыларга
Гомер юрасын.

Парсыз гына кошлар да бит
Оя коралмый.
Елга да бит ике ярсыз
Елга булалмый.

*Кушымта.*

Алда әле, алда булсын
Бәхет-шатлыгың!
Парлылыкны көтеп торсын
Тигез картлыгың.

*Кушымта.*